РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ
ЧЕРЕМШАНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
ул. Советская, д.32, село
Черемшан, 423100

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 32е йорт, Чирмешән
авылы, 423100

тел./факс +7(84396) 2-59-00, email: cheremshan@tatar.ru, http://cheremshan.tatarstan.ru

24 июль 2023 ел №190

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районы Советы
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау турында» 2021 елның 18 ноябрендәге № 76 Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында»

«Россия Федерациясе субъектларында иҗтимагый хакимиятне оештыруның гомуми принциплары турында» 2021 елның 21 декабрендәге № 414-ФЗ, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 05 декабрендәге № 498-ФЗ Федераль законнар, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2023 елның 10 июлендәге №286-ФЗ Федераль закон, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы «Чирмешән муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. 6.5 нче пунктны яңа редакциядә «Мәнфәгатьләр конфликты ягы булган муниципаль хезмәткәрләрнең мәнфәгатьләр конфликтын булдырмау яки җайга салу буенча чаралар күрмәве муниципаль хезмәткәрне федераль законнар белән билгеләнгән очраклардан тыш муниципаль хезмәттән азат итүгә китерә торган хокук бозу булып тора» дип бәян итәргә.

2. 18 бүлекнең 18.3 пунктының 1 пунктчасын бәян итәргә: «1) Россия Федерациясе Президенты хакимиятенең вәкаләтле бүлеге тарафыннан «Коррупциягә каршы тору турында» 2008 елның 25 декабрендәге № 273-ФЗ Федераль законның 13_4 статьясы нигезендә коррупция һәм башка хокук бозуларны профилактикалау буенча тиешле муниципаль органның кадрлар хезмәте бүлекчәсе тарафыннан үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләре турында доклад».

3. Әлеге карарны рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Башлыгы урынбасарына, Совет рәисе урынбасарына йөкләргә.

Чирмешән муниципаль районы Башлыгы,
Татарстан Республикасы Чирмешән
муниципаль районы Советы рәисе Р.Т. Айбатов